ГЛАВА ЯМБУЛАТОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯМБУЛАТ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

26.11.2024 — Ямбулат авылы — № 3

Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авыл җирлегенең
Казыляры авылында гражданнар арасында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча
гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авыл җирлеге Уставының 24 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2024 елның 07 декабренә Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авыл җирлегенең Казыляры авылында гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авыл җирлегенең Казыльяры авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда 6800 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?:
- традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар урнаштыру, төзекләндерү;

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча: Казыльяры авылы, Урман урамы, 28 нче номерлы торак йорт янында 10.00 сәгатьтә үткәрергә.

4. Ямбулат авыл җирлегенең Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Ямбулат авыл җирлеге башлыгы — М.А.Жестков